КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 гыйнвар г.Казань № 32

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комисиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү турында» 2016 ел, 2 декабрь, 885 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 август, 683 нче; 2019 ел, 9 август, 669 нчы, 2020 ел, 13 июль, 586 нчы, 2023 ел, 2 май, 550 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалары эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга конкурс үткәрү буенча конкурс комисиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

конкурс комиссиясе составыннан Р.Р.Гыйззәтовны, М.Р.Хисамиевны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Порсева Дарья натольевнаны | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының матбугат хезмәтләре һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлегенең баш белгечен, конкурс комиссиясе секретарен |

| | |
|---|---|
| Шакиров Илнур Ирек улын | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгын (килешү буенча) |

Кадыйров Тимур Рәфкать улы  вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, «Татарстан Республикасы Халыклары дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Козлов Вадим Евгеньевич вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Психологик һәм дисциплинаара тикшеренүләрнең федераль фәнни үзәге» федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе директоры киңәшчесе (килешү буенча)»;

Пелевин Олег Владимировичның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары».

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 24 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин